2021

**ГОД РОДНЫХ ЯЗЫКОВ И НАРОДНОГО ЕДИНСТВА В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН**
**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА ТУГАН ТЕЛЛӘР ҺӘМ ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫ**




Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение “Алабердинская средняя общеобразовательная школа” Тетюшского муниципального района РТ
Татарстан республикасы Тәтеш муниципаль районы “Алабирде урта гомуми белем бирү мәктәбе” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе



Бүгенге көндә Алабирде урта гомуми белем бирү мәктәбендә укыту телләре –рус теле һәм татар теле. Мәктәптә Алабирде, Зур Әтрәч, Кече Әтрәч, Ямбакты, Никифорово, Байраш,Чолы авылыннан 74 укучы белем ала.

1987 нче елдан бирле мәктәп җитәкчесе вазифасын Гарифуллин Ваһап Юныс улы башкара. Татар теле укытучылары- Гарифуллина Л.Р., Заһидуллина Ә.Г. Рус теле укытучылары- Шәйхетдинова И.Г., Заһидуллина Ә.Т., Гарифуллина Э.Х. Үз эшләрен намус белән башкарган башлангыч сыйныф укытучылары- Сөләйманова Зөлфирә, Нигматуллина Люция, Җәләлиева Гөлфруз, Шәйхетдинова Гөлназ, Гарифуллина Әльфинур балаларга туган телләрендә белем бирәләр

Эй, мәктәбем, белем учагы,
Син гомернең иң гүзәл чагы!



Дөньяда иң-иң матур ил
Ул минем туган илем.
Дөньяда иң-иң матур тел
Ул минем туган телем.
Туган телемдә сөйләшеп,
Яшим мин туган илдә.
“Туган ил” дигән сүзне дә
Әйтәм мин туган телдә.

Родной язык – богатое наследство,
Пришедшее из глубины веков.
Ты отражаешь мысли человека,
Ты помогаешь выразить любовь.

2021

ГОД РОДНЫХ ЯЗЫКОВ И НАРОДНОГО ЕДИНСТВА
В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА
ТУГАН ТЕЛЛӘР ҺӘМ ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫ

**2021 нче елның 18 нче марты. Тәтеш муниципаль районында Бөтенроссия һәм Республика бәйгеләрендә җиңүче укучылар белән очрашу. Алабирде урта мәктәбенең югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы Гарифуллина Ландыш Ринат кызының чыгышы.**

Бүгенге чыгышымны һәр татар кешесе өчен мөһим булган сүзләр белән башлап, телебезгә, милләтебезгә булган хөрмәтне йөрәгем аша җиткерергә телим.

Татар укучысы! Бел! Син сөйләшкән тел дистәләгән гасырлар
буена чарланып, иң камил телләр дәрәҗәсенә
күтәрелгән. Синең телеңдә катлаулы фәнни хезмәтләр
дә, илаһи төшенчәләр дә, гүзәл әдәби әсәрләр дә язылган.
Аны хөрмәт ит, сакла һәм үстер.

(“Татарның әхлакый кодексы”ннан)

Мин- 32 еллык укытучылык стажы булган татар теле һәм әдәбияты укытучысы. Үземнең төп эшем итеп туган телгә өйрәтүне, әдәбият дөньясына мәхәббәт тәрбияләүне алга куйган гади авыл укытучысы. Кем соң син, татар теле укытучысы? Алга куйган максатың нинди? дигән сораулар борчыган вакытта, мин гади генә җавап бирер идем. Кешегә һава ни өчен кирәк, нигә аны сулыйбыз дип сорамыйбыз бит. Табигый күренеш. Һава сулар өчен, яшәр өчен кирәк. Туган телне белүдә дә һава кебек ихтыяҗ тудырырга кирәк. Минем максатым- телебезнең дәрәҗәсен арттыру өстендә эшләү.

“Туган телебезне, җырларны, моңны саклау- бу күрсәтмә дә, вазыйфа да булырга тиеш түгел. Бу һәр татар кешесенең үз халкына булган мәхәббәте, тарихына хөрмәтен күрсәтә алган әхлакый бурычы!”

Без- киләчәк буын тәрбияләүдә үзебездән бик күп көч куючы бүгенге заман укытучылары. Бүген каршыбызда утырган, белем алган балалар киләчәктә әти-әниләр, җәмгыятебезнең тоткасы буласы кешеләр. Нәрсә күрсәтә алабыз, нәрсә өйрәтергә тырышабыз- барысы безнең кулда. Искә төшерик әле: укытучыбызны үрнәк итеп куеп, укытучылык юлыннан киттек. Әти-әнинең сүзләрен бүген дә олы итеп искә алабыз, тәрбия процессында кулланабыз. Балалар күзебезгә карап торганда, бездән кыйммәтле сүзләр көткәндә, без үзебезнең эшне намус белән эшләргә тиеш дип саныйм мин.

2021 нче ел- Туган телләр һәм Халыклар бердәмлеге елы дип игълан ителгәч, күңелдә ышаныч, ныклык, җаваплылык хисләре тагын да артты. Минем өчен һәр узган ел-Туган тел елы булып күңелдә яши. Минем мөхитем- тел дөньясы, татар әдәбияты дөньясы.

Илдә, җәмгыятьтә бара торган үзгәрешләр татар теле һәм әдәбияты укытучылары алдына яңа

максат – бурычлар куйды. Укучыларның белем алу эшчәнлеге белән идарә итү , рухи һәм физик үсешен, кызыксынучанлыгын үстерүгә булышу – шуларның иң мөһиме. 21 нче гасырда яшәвебезне , яңа техник мөмкинлекләр базасының югары дәрәҗәдә булуын уйлаган очракта , максатның катлаулы булуын күрәбез. Димәк, яңалыкка омтылучы, заман сулышын тоючы, белемен өзлексез камилләштерүче, укыту- тәрбия эшенә иҗади якын килүче укытучы гына бу максатны тормышка ашыра ала. Укытучы иҗади шәхес булырга тиеш. Педагогик эшчәнлектә иҗадилык-бу, беренче чиратта, яңалыкка, үзгәрүчәнлеккә омтылу.

Үз фәненә балаларда кызыксыну уята алган укытучы- үз эшенең остасы инде ул.

Фикереңне төпле итеп бирә алу, телнең тарихын, матур әдәбият әсәрләренең кыйммәтен тоеп әзерләнгән укучы – республика бәйгеләрендә көч сынаша ала торган дәрәҗәгә җиткән укучы инде ул. Республика күләмендә үткәрелә торган фән бәйгеләрендә катнашып җиңүгә ирешү- бу укучы һәм еллар дәвамында аның белән эшләгән укытучы өчен матур күренеш. Хезмәтнең нәтиҗәсен күрү – бала, әти-әни, укытучы, мәктәп, район өчен зур дәрәҗә дип әйтәсем килә.

Алабирде урта мәктәбе укучылары татар теле һәм әдәбияты, рус теле һәм әдәбияты, тарих-җәмгыять фәннәреннән республика бәйгеләрендә уңышлы чыгыш ясыйлар. Мингалиев Назил 3 ел, Загидуллина Ралинә 4 ел, Салеева Йолдыз 3ел рәттән үзләрен югары баскычта күрсәттеләр. Бүген зур горурлык хисләре белән, республика бәйгеләрендә уңышлар яулаган укучыларның исемнәрен кабатлыйсым килә: Мингалиева Фирүзә, Миннуллина Румия, Шамгуллина Венера, Шамгуллина Илмира, Якупов Нәфис, Гарифуллина Айгөл, Халилова Гөлинә, Нигматуллина Гүзәл, Мингалиев Назил, Шебалова Алена,Загидуллина Ралинә, Гаязова Гөлинә, Салеева Йолдыз, Шайхутдинова Адилә...

Республика олимпиадасында иң дулкынландырган мизгел- җиңүче укучыларның исемнәрен көтү һәм алар арасында Тәтеш районы Алабирде мәктәбе дигән сүзне ишетү. Ул сүзләр укучы һәм укытучы йөрәгенә бер моң булып үтеп керә һәм күз яшьләренә әверелә. Бу шатлык яшьләре, рәхмәт яшьләре икәнен икесе дә аңлый. Шушы сүзләрне ел саен республика сәхнәсеннән ишеттергән укучыларымның киләчәк тормышларында да уңышларга ирешеп, олы бәхеттә яшәүләрен телим.

Гомер буе үз фәненә тугры булып калган, каршы искән җилләргә бирешмәгән һәм алга өндәгән татар теле укытучысының девизы: (дәвамы 4 нче биттә)

2021

ГОД РОДНЫХ ЯЗЫКОВ И НАРОДНОГО ЕДИНСТВА
В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА
ТУГАН ТЕЛЛӘР ҺӘМ ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫ

Гомеремдә бик күп галим,
Мөгаллимнәр бирде гыйлем.
Күңелемә иң якыны,
Укытканы- татар телем.
Анам сөте белән сеңгән
Һәрбер сузык,ымлык,сүзне
Җөмләләргә оештырам,
Акыл тажы-җөмлә төздем.
Башкалар һич үпкәләмәс,
Телне алга куйган өчен.
Тәрҗемәсез кабул итәм...
Шуңа тәмле,күркәм, өстен!
Ул булганда адашмабыз,
Юлым туры,нурлы көнем.
Күз карасы кебек саклыйм
Анам телен- татар телен!



Каждый язык-это целый мир. Язык не только предмет для изучения, но и живая душа народа, его радость, боль, память, сокровище. Он должен вызвать у каждого человека горячую любовь, признательность, трепетное отношение.
Главное назначение языка-средство общения людей. Он неразрывно связан с мышлением, сознанием человека, служит средством формирования и выражения мыслей.

**Хорошую речь хорошо и слушать.**
**Каков ум, такова и речь.**
**Кто русским языком владеет, тот большую силу имеет.**

Тел турында мәкальләр.

1.Акыллының теле күңелендә,
Тиленең акылы телендә.
2.Теле белән күктәге айны йөртә белгән,
Кулы белән казандагы майны эретә белмәгән.
3.Теле озын булмаганның гомере озын булыр.
4.Сүз бер көнлек, тел гомерлек.

2021

ГОД РОДНЫХ ЯЗЫКОВ И НАРОДНОГО ЕДИНСТВА
В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА
ТУГАН ТЕЛЛӘР ҺӘМ ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫ



***2020/2021 нче уку елында югары күрсәткечләргә ирешкән уку алдынгысы, татар әдәбияты һәм рус әдәбияты фәннәре буенча республика олимпиадалары призёры, Бөтенроссия “Илһам” яшь язучылар бәйгесендә 2 нче урынга лаек булган 11 нче сыйныф укучысы Салеева Йолдызның иҗади язмасы.***

Әгәр хыяллар кешегә канат куя икән дип әйтсәләр, мин моңа ышанам. Үзеңдә канатлар тою очарга этәрә, үзеңдә булган хисләрне сөйлисе, уртаклашасы килә. Бүген мин үземне “Журналистика мәктәбе”нең өйрәнчек укучысы итеп хис итәм һәм, әлбәттә, үземнең беренче язмаларым белән уртаклашырга телим. Бүген үземнең героемны ачарга тырышачакмын. Ә инде кулга каләм алуыма этәргеч булган сәбәпләр дип түбәндәгеләрне саныйм:

- 2018 нче елда дустыбыз Загидуллина Ралинә үзенең язмалары белән республика бәйгеләрендә уңышлы чыгыш ясады һәм бүгенге көндә КФУ ның журналистика факультетында белем ала. Ә нигә дип миңа башлап җибәрмәскә бу эшне! Киләчәк һөнәреңне шулай күз алдына китерәсең икән, бүген үк каләмеңне чарлат!
- Мәктәбебездә “Журналист булу җиңелме? “түгәрәге бөтен көченә эшләп килә. Теләге булган һәрберебез өчен ишекләр ачык!
- Мәктәптә чыгарыла торган гәҗиткә мәкаләләрне кем яза? Анысын да миңа йөкләделәр.
- Холкыма килгәндә, кечкенә генә булсам да, туры сүзле диләр.
- Әлбәттә, зур хыялым бар. Хыялыма ирешү өчен тырышлыгым җитәрлек. Әкиятләргә дә ышанып яшәргә кирәк, әгәр шулай булмаса, яшәүнең кызыгы булмас иде.

**“Үзем турында үзем”**

**Интервью**

-Исәнме, Йолдыз. Кем син, кайлардан?

-Кызык сорау. Мин дә сезнеңчә җавап бирим әле. Мин - Җир кызы. Татарстанның иң матур җирендә, Тау ягы дип йөртелә торган гаҗәеп серле табигать кочагында урнашкан Олы Әтрәч авылында туганмын. Тарих битләрендә “Мең өйле Шонгаты” дип йөртелгән Әтрәч авылы инде ул. Шифалы суын эчеп, назлы җилләрендә тибрәнеп, ай үсәсен көн үсеп дигәндәй, бүген инде 11 нче сыйныф укучысы булып укып йөрим. Салеева Йолдыз Фәнил кызы – Алабирде урта мәктәбенең бер укучысы булам.

- Синең белән сөйләшергә җиңел икән, Йолдыз. Дусларың белән дә аралашырга яратасыңмы?

- Әлбәттә, сөйләшергә яратам! Дусларым күп минем. Авыл мәктәбенең бик әйбәт ягы бар: анда һәрберебез бер гаилә булып яшибез, бер-беребезне яттан беләбез. Ә сыйныфыбыз турында горурланып, "Безнекеләр!" дип әйтә алам. Берне 13 кә бүлеп яшибез. 13 нчесе - сыйныф җитәкчебез Илсояр апа. Бер йодрык, бер бөтен дигәндәй, утка да суга да бергә!

- Йолдыз, әңгәмәне башлап җибәргәнбез икән, исемең турында да сөйләп җибәр инде. Кем кушты сиңа исемне?

- Мин бу сорауны күп тапкырлар ишеткән булды. Әллә Йолдыз булганга сорыйлар. Хәтерлисезме, Рафаэль Төхфәтуллинның "Йолдызым" әсәрендә шул сорауны кыз әнисенә бирә. Мин дә әниемә бирдем бу сорауны ."Кызым, йолдызым минем! Исемең, җисемеңнең маягы булып, сиңа юл яктыртып торсын, үрләргә менәргә булышсын !" - дигән җавап ишеттем. Әнием кушкан, яратып үстергән, хәзер дә гел уңышлар гына теләп тора.

- Ә гаиләң турында ни сөйләрсең, Йолдыз.

- Гаиләм – минем олы байлыгым. Мин бит дәү әти-дәү әни тәрбиясендә үскән иркә кыз. Бүген үзем аларны тәрбияләшергә булышам. Әнием - минем өчен үрнәк. Аның җитез, эшлекле, намуслы булуын күзәтәм һәм горурланам. Ул сүзе белән генә тәрбияләми , ә эше белән күрсәтә, өйрәтә.

- Мин синең өчен шат, Йолдыз. Рәхәтләнеп, яратып сөйлисең. Сине үземнең күптәнге танышым дип уйлый башладым.

- Ә мин синең җитди сорауларың алда икәнен белеп, аларны биргәнеңне көтеп торам.

- Әйе, син хаклы. Бүгенге соравым синең җиңүләрең турында. Җиңүләргә илткән юлың җиңелме?

- Җиңүләр юлы беркемнең дә җиңел була алмыйдыр ул, минемчә. Җиңү сүзе бит ул күп мәгънәне белдерә. Минем беренче җиңүем бик кызыклы. Мин үземнең куркуны җиңәргә өйрәндем. Караңгылыктан куркуны! Нәтиҗәсе, һичшиксез уңай! Икенчесе – кирелегемне җиңү. Авыр булса да, анысын да җиңдем. Үзеңнең һәрвакытта да дөрес түгеллегеңне тануы бик җиңел түгел икән ул! Укуымда булган җиңүләр өчен дә күп тырышырга туры килә. Дәресләргә көн дә әзерләнеп йөрим, сәбәпсез калдырмыйм. Нәрсәдер килеп чыкмый икән, утырып еларга да күп сорамыйм. Аннары инде җил-давылга каршы барырлык көч тоям үземдә. Чирекнең ахыргы атнасында гына түгел, һәр көнендә әзерлек белән килгән 5 лемнең бәясен яхшы беләм!

- Соңгы җиңүең дип нәрсәне әйтер идең?

- Аның турында сөйлисе дә сөйлисе килә. Мәктәптән кайткannan соң, телефонымда "Республика олимпиадасына үткәнбез, Йолдыз. Нәрсә әйтерсең икән?" дигән сорауны укыгач, берни уйламыйча, "Барабыз!" дип язып җибәрдем һәм аптырап калдым. Бары бер атна вакыт калган икән ич! Шул атна эчендә күпме уй уйладым, укыдым, анализладым.

2021

ГОД РОДНЫХ ЯЗЫКОВ И НАРОДНОГО ЕДИНСТВА
В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА
ТУГАН ТЕЛЛӘР ҺӘМ ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫ

“Дуслык” лагерена баргач, алда торган эшнең никадәр җаваплы икәнен күрдем. Берсеннән-берсе белемле балалар белән тулган бүлмәләрдә әдәбияттан бәйгегә әзерлек бара иде. Укытучым белән күзгә-күз карашып, соңгы көчне җыйдык. Һәм нәтиҗәсе : Тәтеш районы Алабирде мәктәбенең 9 нчы сыйныф укучысы Салеева Йолдыз - татар әдәбияты буенча республика призеры!.

-Көнләшүчеләр булдымы соң?

- Юк дип әйтәсем килә. Без бер-беребезнең җиңүләренә шатланырга, алар белән горурланырга өйрәнгән бит. Катнаш, үзеңне күрсәт. Укытучылар һәрвакыт ярдәм итәргә әзер. Быел мәктәбебез буенча муниципаль этапта 38 җиңүче һәм призерыбыз бар ! 4 укучыбыз район данын республика күләмендә яклый! Мине дә бөтен мәктәп белән алкышлап, шатланып каршы алдылар. Директорыбыз Ваһап абый кочаклап ук алды, күзләрендә шатлык яшьләре иде. Шундый кешеләр арасында рәхәтләнеп укыйсы да укыйсы килә.

- Җиңелгән вакытларың булдымы?

- Ничек булмасын ди инде. Мин дә кеше ләбаса. Ләкин җиңелүләр аша җиңүгә бара белергә кирәк . Туктап калмаска, тырышырга.

- Хыялларың турында сереңне чишсәң, Йолдыз исемле бер кыз белән таныштым дип рәхәтләнеп әйтә алачакмын.

- Хыяллар дөньясында яшим. Фантазиям көчле минем. Киләчәгемне журналистика белән бәйлисем килә. Аңлыйм: күп тырышлык , үҗәтлек таләп ителә. Телемне саклаучылар рәтендә буласым килә. Көнелдән белгән сүзләремне кабатлыйм “Татар укучы! Бел! Син сөйләшкән тел дистәләгән гасырлар буена чарланып, иң камил телләр дәрәҗәсенә күтәрелгән. Аны хөрмәт ит, сакла һәм үстер!” Тырышачакмын. Сүз бирәм!

-Әңгәмәң өчен зур рәхмәт. Мин сиңа ышанам. Йолдызың гел маяк булсын!



23 апреля 2021 года в МИЦ Деревни Универсиады состоялся Всероссийский форум родных языков. В рамках Всероссийского конкурса юных поэтов и писателей «Илһам» обучающиеся нашей школы Мавлюдова Ф.,Сабирова Р.были награждены дипломами лауреатов, Салеева Ю. признана призёром республиканского этапа. Поздравляем всех и желаем дальнейших творческих побед!

2021

ГОД РОДНЫХ ЯЗЫКОВ И НАРОДНОГО ЕДИНСТВА
В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА
ТУГАН ТЕЛЛӘР ҺӘМ ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫ

**21 нче февраль - Халыкара туган тел көне.**

Өлкән сыйныф укучылары катнашында дәрес-уен үткәрү.

Гарифуллина Ландыш Ринат кызы, югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

2020-2021 нче уку елы

Җиһазлау: сыйныф тактасында тел турында әйтем-мәкальләр,бөек шәхесләрнең туган тел турында язган шигырь юллары, интерактив такта,музыкаль бизәлеш.
Максат: Туган телебез – татар теленә мәхәббәт уяту, татар теле һәм әдәбияты буенча укучыларның белемнәрен бәяләү,аралашу культурасын үстерү
Уенның тәртибе: 1.Визит карточкасы - презентация 2.”Иң грамоталы укучы” ( диктант )- командадан 1 укучы 3.”Нәфис сүз остасы” (Бөек шагыйребез Габдулла Тукай шигырен яттан сөйләү) – командадан 1 укучы 4.”Мин кулыма кәлам алам” (инша бәйгесе) – командадан 1 кеше 5.Габдулла Тукай,Фәнис Яруллин,Муса Җәлил иҗатлары буенча викторина сораулары (команда) 6.Кроссворд – башваткыч (команда) 7.Мәкаль әйтешү уены (алып баручы укытучы- капитан) 8.Иң күп сүз уйлап табучы команда 9 Йомгаклау.Нәтиҗә ясау,бүләкләү
Талгын көй астында укытучы бәйрәм тантанасын башлап җибәрә. Татар теле фәне буенча республика призёры 11 нче сыйныф укучысы Салеева Йолдызны котлау, истәлекле бүләк тапшыру.1 нче сыйныф укучылары туган тел турында шигырьләр сөйлиләр. Халыкара туган тел көне турында укытучының чыгышы тыңланыла..

1. Һәр команда визит карточкасын тәкъдим итә.

2. Укучыларның грамоталылык дәрәҗәләрен тикшерү конкурсы.(диктант)

“Табигать үзенең үзгәрмәс кануннары белән яши бирә. Без, кешеләр генә, аңа үз белдегебез белән үзгәртмәләр кертергә тырышып яши бирәбез .Ә вакыт дигәнең барыбер барын да үз урынына куячак.

Соңгы вакытта 6 яшьлек улым әллә нинди фәлсәфи сораулар биреп йөдәтә. Бу сорауларга җавап эзли - эзли кояшны ,йолдызларны урап ,бар җиһанны гизеп ,соңында Мәккә җиренә төшәргә туры килде миңа. Кыйблага карап, намаз укуның мәгънәсенә дә тукталдык без. Бар җавапларым арасында улыма иң тәэсир иткәне кәгъбә ташы булды. Гөнаһлы җир йөзенә хаклык иңгәч кенә кәгъбә ташының агарасын белеп аптырады ул.”(Н.Гариф)

3. Нәфис сүз осталарын бәяләү: “Милли моңнар”,”Таз”, “Ана догасы” шигырьләрен сәнгатьле сөйләү

4. Шагыйрь кулы, кара савыты, каләмне сурәтләгән сын буенча “Мин кулыма каләм алдым” иҗат бәйгесе башлана. Укучылар 10 минут эчендә образ буенча үз вариантларын тәкъдим итәләр.

МУЗЫКАЛЬ ПАУЗА (Уен коралларында татар халык көйләренә тезмә)

5. Викторина уены башлана.

Өй эше 1 атна алдан бирелә. Укучылар Габдулла Тукай, Муса Җәлил, Фәнис Яруллиннарның биографияләрен кабатларга, шигырьләрен искә төшерергә, өстәмә чыганаклар буенча әзерләнергә тиешләр.

***Сораулар** (слайдта күрсәтелә бара)*:

1). Габдулла Тукайның беренче шигырьләр җыентыгы кайда һәм нинди исем белән нәшер ителә? (Казан Шәрәф мәтбугаты,”Габдулла Тукаев шигырьләре” исеме белән. 1907 нче ел, 15 ноябрь )

2). Габдулла Тукайның 125 еллык юбилее уңаеннан “Шүрәле” поэмасы нинди телгә тәрҗемә ителә? (Моңа кадәр 15 телдә (татар, гарәп, рус, уйгур, фарсы ,башкорт, казах, төрек ,венгр, француз, немец, таҗик, үзбәк, кытаө, инглиз) була, удмурт теленә тәрҗемә ителә.

3).Казанда Габдулла Тукайның шәхси 5 әйбере саклана. Нинди әйберләр? (кара савыты (1912 елда Петербургка сәяхәте вакытында татар балалары бүләк иткән,) кара вельвет түбәтәй (1908 нче елда фотога төшә), җиң каптыргычлары (чит илдән алып кайтып бүләк итәләр), фаянс шкатулка (апасы Газизәгә беренче гонорар акчасына сатып алган була), юл кәрзине)

4).Габдулла Тукайны Микоян фабрикасы белән нәрсә якынайта? (1946 нчы елда60 еллык юбилее уңаеннан шушу кондитер фабрикасында “Тукай” исемле яңа төр конфет чыгаралар. Тышында шагыйрьнең рәсеме була)

5).Тукайның вафатына 10 ел булган көнне М.Җәлил “Тукай каберендә” исемле шигырен яза. Аңа ничә яшь була? (17 яшь)

6).Муса Җәлил нинди балалар журналлары оештыруда катнаша? (“Кечкенә иптәшләр” ,”Октябрь баласы” )

7).Муса Җәлилгә һәм аның көрәштәшләренә ничәнче елда һәм нинди шәһәрдә суд була? (1944, февраль, Дрезден шәһәре)

8).Фәнис Яруллинның беренче мөстәкыйль китабының исеме ? (1964, ”Мин тормышны яратам”)

9).” Әтием 1913 нче елларда вак сәүдә эшенә катнашып китә, ләкин, бөлеп, бөтен йорт-җирен сатып, шәһәргә китәргә мәҗбүр була .Шәһәрдә төрле кәсепкә тотынып карый: толчокта иске-москы җыйнап сата ,пекарняда эшли, вак кул сәүдәсе белән шөгыльләнә. Тормышын җайлый алмый. 1918 нче елда авылга кайта ,1919нчы елда авырып үлә. ” Игътибар сорау: бу өзек кемнең әтисе турында? (М.Җәлил )

10). Казан Кремле янында М.Җәлилгә һәм җәлилчеләргә һәйкәл – комплекс ничәнче елда куелган? (1966)

11).”Бер гашыйк егеткә сөйгән кызы: ”Сөюеңне раслар өчен миңа әниеңнең йөрәген алып кил”, - ди .Мәхәббәттән күзе томаланган егет анасының күкрәгеннән умырып ала да сөйгән кызы янына ашыга. Барганда егет абынып егыла. Шунда ананың канлы йөрәге : ”Берәр җирең авыртмадымы, улым?”- дип сорый.” Сорау: Фәнис Яруллинның “Ана турында баллада”сы белән әлеге легендада нинди охшашлык бар? (Әҗәл 10 ел гомер өстәргә җыенгач ,баласына өстәргә куша)

12).Татарстанда ничәнче ел Тукай елы дип игълан ителде? (2011)

13).Ничәнче елда Тукайның мәшһүр исеме Юнесконың тарихи- мәдәни ядкарьләр исемлегенә кертелгән? (1986 нчы елда , 100 еллык юбилей уңаеннан)

14).” Алтыннан кече түгел мин ,
Ипидән олы түгел.
Үлемнән көчле түгел мин ,
Тик язмыш колы түгел .” дигән юлларны кем язган?

15).Ничәнче елда Фәнис Яруллинга Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелә? (1995, “Җан авазы” китабы өчен)

Искәрмә : Һәр команда, сан әйтеп, үзенә сорауны үзе сайлый ала.

6.Укытучы 13 сүзле кроссворд тәкъдим итә . Сораулар гомуми күзәтүне тикшерү өчен төзелгән.

1) Җанлы җансызны кыйный ,җансыз кычкырып елый.
2)Күзе дә юк , колагы да юк, үзе сукырны җитәкли.
3)Бер тавык тавык, ә ике тавык нәрсә?
4)Үтенү сүзенең синонимы
5)Тиз ашый, вак чәйни, үзе йотмый, башкага бирми.
6)Милләт
7)Авыру исеме
8)Һөнәр исеме
9)Яшелчә исеме
10)Карак сүзенең синонимы
11)Аяк асты ...
13)... ипие
14)Аның эче буш

МУЗЫКАЛЬ ПАУЗА
7.Мәкаль әйтешү уены капитан һәм алып баручы укытучы арасында үткәрелә. Укытучы башлый, укучы дәвам итә.

Иң татлы тел- туган тел, (анаң сөйләп торган тел).
Телне тешләп өзеп булмый, (сөйләми дә түзеп булмый).
Бик татлы булма , кабып йотарлар, бик ачы булма ,(төкереп ташларлар).
Бит күрке күз, (тел күрке сүз).
Тел – ананың теләге, (тел – ананың баласына иң кадерле бүләге).
Тел –кылыч, тиешсез җирдә тый, (тиешле җирдә кый).
Телләләр халык булып дөньяга чыккан, телсезләр балык булып дәрьяда калган, (бакылдыклар бака булып баткакта яталар ди ).
Телең белән узма, (белемең белән уз).
Төче коймак пешергән кешегә бар, (төче телле кешегә барма).
Теле белән күктәге майны эретә белгән, (кулы белән казандагы майны эретә белгән).
Аягы пычрак – өй пычратыр, ( теле пычрак –кеше пычратыр).
Бер ялган сөйләсәң, (9 дөресеңә дә ышанмаслар).

8.Тизлеккә һәм күп сүзләр белүгә уен. 1 минут эчендә исем сүз төркеменә кергән сүзләр уйлап тап. КАЛӘМДӘШЛӘР сүзе.
9.Йомгаклау өлеше. Һәр уен буенча җыелган баллар әйтелә, җиңүче укучылар, командалар билгеләнелә. Бүләкләү тантанасы.
Алып баручы укытучы Илдар Юзеевның “Туган телем” шигыре белән укучыларга мөрәҗәгать итә. Габдулла Тукайның “Туган тел “ шигыренә язылган җыр белән уен тәмамлана. Истәлек өчен фотога төшү, комментарийлар.

2021

ГОД РОДНЫХ ЯЗЫКОВ И НАРОДНОГО ЕДИНСТВА
В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА
ТУГАН ТЕЛЛӘР ҺӘМ ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫ

6 марта в школе прошёл школьный этап Национального детского фестиваля народного творчества «Без бергә”. Фестиваль-конкурс собрал самых талантливых школьников. Юные таланты демонстрировали своё актёрское мастерство.






16 февраля 2021 года учитель истории и обществознания Яруллина К.Л. провела Парламентский урок. Учащиеся узнали о действующих программах РТ в сфере национальной политики, об успехах в их реализации. С положением об образовательной системе района, с достижениями аграрного производства обучающихся познакомил депутат сельского поселения Гарифуллин В.Ю. По итогам муниципального этапа республиканского конкурса сочинений «Парламентский урок» Шарафиева Р. , Салеева Ю стали победителями. Учитель родного языка и литературы Гарифуллина Л.Р. была на встрече с Председателем Госсовета РТ Мухаметшиным Ф.Х



18 апреля в спортивно-оздоровительном комплексе «Ак Барс» г. Тетюши прошел турнир по шахматам среди юношей и девушек, посвященный Дню космонавтики в России, Году родных языков и народного единства на призы ПОУ Тетюшская автошкола ДОСААФ Республики Татарстан. Более 50 спортсменов и любителей шахмат соревновались в 4-х возрастных группах за титул победителя и призера. Обучающиеся нашей школы выступили результативно. 2 место – Загидуллина Алия, 3 место –Шарафиева Рузина, 3 место - Замалетдинова Алсу.



2021

ГОД РОДНЫХ ЯЗЫКОВ И НАРОДНОГО ЕДИНСТВА
В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА
ТУГАН ТЕЛЛӘР ҺӘМ ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫ

**Внеклассное мероприятие по русскому языку для 5-7 кл.**

**Цель**: создание условий для формирования мотивации учащихся к изучению русского языка.

**Задачи:**

1. Развитие логического и творческого мышления.
2. Развитие внимания, памяти, наблюдательности, мыслительных процессов.
3. Развитие навыков командной работы.

**Пояснительная записка.**

Форма проведения интеллектуальной игры очень интересна для учащихся любого возраста, так как предполагает острый дух соперничества. Проведение таких игр способствует повышению интеллектуального уровня школьников, развитию эвристических способностей, сплочению детских коллективов. Использовать такую форму можно как на уроке, так и во внеклассной работе.

**1 конкурс. РАЗМИНКА.**

**Ведущий:**

Ответьте, о ком или о чем говорится.

1) «Личное дело» ученика для служебного пользования его родителей (дневник).
2) Что такое ручкохранилище? (пенал).
3) Земля, которую может покрутить любой желающий (глобус).
4) Его долгожданный звук является божественной музыкой для не выучившего урок школьника (звонок).
5) Как называется школьный известняк? (мел).
6) Предмет, опровергающий поговорку «Что написано пером, не вырубишь топором» (ластик).
7) Слово белый по отношению к слову черный (антоним).
8) Пишется так же, но смысл другой (омоним).
9) Что есть у дерева, растущего в лесу, и у слова дерево, написанного на бумаге? (корень).
10) Он бывает между корнем и окончанием (суффикс).
11) В какую букву надо поместить слово-согласие, чтобы получить продукт таяния снега? (в О да.)
12) Именно этим «инструментом», являющимся частью речи, А.С. Пушкин призвал «жечь сердца людей» (глагол).

**2 Конкурс. ПОСТИЖЕНИЕ НАРОДНОЙ МУДРОСТИ.**

**Ведущий:**

Уже давно никто не спорит с утверждением о том, что русский язык – самый богатый в мире. Одной из его ценностей является огромное количество пословиц и поговорок, которые пришли к нам из глубины веков и до сих пор создаются устным народным творчеством. В них выражена народная мудрость, и употребление их в вашей речи поможет сделать ее более яркой, самобытной, интересной.

Сейчас я хочу предложить вам ответить на вопросы: вспомните соответствующие пословицы и поговорки, сформулируйте их дословно. В задании могут встретиться и фразеологические обороты, которые приближены к поговоркам.

1. Он здоровый, в здоровом теле... (здоровый дух).
2. Часть одежды, которую рекомендуют держать шире... (карман шире).
3. У него глаза велики... (у страха).
4. Только там бывает бесплатный сыр... (в мышеловке).
5. Ее ждут, сидя у моря... (погоды).
6. Эта часть предмета бывает золотой... (середина).
7. Какую еду иногда просит обувь у ее незадачливого владельца? (кашу – «сапоги каши просят»).

**3 Конкурс. «ЧТО ЭТО? КТО ЭТО?»**
**Ведущий:**
Ответьте на вопросы: что это? кто это?
Этот автор спит в портфеле... АВТОРУЧКА
Этот пони – день недели... ПОНЕДЕЛЬНИК
Этот плот – из полотна... ПОЛОТЕНЦЕ
Этот рак сильней слона... ТРАКТОР
Эта марка ест бананы... МАРТЫШКА
Этот сыр – с лесной поляны... СЫРОЕЖКА

**4 Конкурс. РАССТАВЬТЕ ГЛАСНЫЕ.**
**Ведущий:**
Этот конкурс требует от вас определенной фантазии и большого словарного запаса. Но для начала вспомните, какие буквы называют гласными.
А теперь, пожалуйста, расставьте гласные в предлагаемых вам конструкциях.
Например:
Букву Е
БРТ – БеРеТ
СВР – СеВеР
ВР – ВееР
КЛЩ – КЛеЩ
Команды получают задание на карточках:

| Букву О | Букву А |
|---|---|
| КН – окно | БРН – баран |
| ГРХ – горох | ТК – атака |
| КЛКЛ – колокол | РФ – арфа |
| ТПТ – топот | МРК – марка |
| БЛТ – болт | СТР – астра |
| ПКЙ – покой | КРМН – карман |
| ГРН – горн | БРК – барак |
| ТРН – трон | ШЛШ – шалаш |
| КРК – окорок | ФНТ – фант |
| ГЛТК – глоток | ШРМ – шрам, шарм |
| Букву У | Букву И |
| СД – суд | ПРЗ – приз |
| ШРП – шуруп | РС – рис |
| КСС – уксус | ЛЛЯ – лилия |
| КСТ – куст | ФЛН – филин |
| БРНДК – бурундук | РС – ирис |

**5 Конкурс. РЕДАКТОР.**
**Ведущий:**
В этом конкурсе я проверю ваше умение правильно строить предложения.
Вам предлагаются отрывки из детских сочинений. Найдите ошибку в каждом предложении и объясните, почему нельзя так писать.

Ведущий раздает командам тексты:
1) Я одел пальто и пошел гулять (на себя – надел).
2) Наш класс гремит по всей школе хорошими отметками (известен всей школе).
3) У дороги стоял пожилой гриб (старый).
4) Наша команда проиграла благодаря отсутствию двух ведущих спортсменов (из-за).
5) Она уверена в свои силы (уверена в своих силах).

**6 Конкурс. УСТНАЯ РЕЧЬ. Ведущий:**

В этом конкурсе вам надо соединить фразеологическое сочетание (цифру) с его объяснением (букву).1. Не ударить в грязь лицом.
2. Держать себя в руках.
3. Мелькнуть, как молния.
4. Игра не стоит свеч.
5. Стрелять без промаха.
6. Во что бы то ни стало.
7. Не находить себе места.
8. Вешать голову.
А. Занятие, которое себя не оправдывает.
Б. Обязательно.
В. Очень быстро.
Г. Точно в цель.
Д. Сохранять самообладание.
Е. Показать себя с лучшей стороны.
Ж. Быть в состоянии большого волнения.
З. Огорчаться.   Ключ: 1Е, 2Д, 3В, 4А, 5Г, 6Б, 7Ж, 8З.

**7 Конкурс. ВЕСЕЛАЯ ГРАММАТИКА. Ведущий:**

Поработаем с частями речи. От предложенных имен прилагательных образуйте имена существительные.
Храбрый – храбрость, сильный – сила, гордый – гордость, мудрый – мудрость, грубый – грубость, веселый – веселье, умный – ум, смелый – смелость, добрый – доброта, богатый – богатство, ленивый – лень.

**Ведущий:**

Читает высказывание И.С.Тургенева:"Берегите наш язык, наш прекрасный русский язык – это клад, это достояние, переданное нам нашими предшественниками! Обращайтесь почтительно с этим могущественным орудием; в руках умелых оно в состоянии совершать чудеса".
Мероприятие подготовила и провела Загидуллина А.Т.,учитель русского языка и литературы высшей квалификационной категории



2021

ГОД РОДНЫХ ЯЗЫКОВ И НАРОДНОГО ЕДИНСТВА
В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА
ТУГАН ТЕЛЛӘР ҺӘМ ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫ




Родной язык — народа достоянье,
Он с детства каждому из нас знаком,
Стихи и проза, сказки и преданья,
Все мило нам на языке родном!
Учите, берегите речь родную,
Стихи слагайте, украшая жизнь!
Потомкам передайте речь живую,
Чтоб память о народе сохранить!

***Сохранение языка - сохранение нации***



*Напутствия классиков*

*„Берегите чистоту языка, как святыню! Никогда не употребляйте иностранных слов. Русский язык так богат и гибок, что нам нечего брать у тех, кто беднее нас. “*

*И.С.Тургенев*

*«Изучать родной язык необходимо… чтобы уметь употреблять его для выражения своих мыслей».*

*Н.Г.Чернышевский*

*«Родной язык – это душа нации.
Нации, которая теряет свой подлинный, свой исторический язык,
а вместе с ним и свою психологию, культуру, память о предках».*

*Дмитрий Сергеевич Лихачев*

***Каждый народ должен заботиться о своем языке, изучать его, собирать слова родного языка, составлять справочники и словари. Тогда язык будет "живой", развивающийся. Люди должны беречь родной язык для последующих поколений. Хранить и оберегать язык - важная задача каждого.***

2021

ГОД РОДНЫХ ЯЗЫКОВ И НАРОДНОГО ЕДИНСТВА
В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА
ТУГАН ТЕЛЛӘР ҺӘМ ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫ

Мәңге яшә сәхнә дигән тәхет, синдә хезмәт итү үзе бәхет!

Дәрестән тыш вакытыңны күңелле, файдалы үткәрәсең килсә, рәхим ит! Тәтеш районы Алабирде мәктәбендә күптәннән эшләп килүче театр түгәрәкләренә язылырга була. Татар теле һәм әдәбияты, башлангыч сыйныф укытучылары яратып укучыларны сәхнә тормышы белән таныштыралар. Театр бәйгеләрендә зона, республика сәхнәләрендә беренчелекне алган "Әллүки" берләшмәсе кызлары бүген 10 нчы сыйныфта укыйлар. Җитәкчеләре - Гарифуллина Ландыш Ринатовна. Алар 5 нче сыйныфтан бирле сәхнәдә уйнап, осталык бәйгеләрен уңышлы уздылар. "Ният"- зона, Туфан Миңнуллин исемендәге республика конференцияләрендә "Кәрлә мәктәп баласы" 1 нче урын, "Авыл эте Акбай" лауреат, "Практикантлар килгән безгә" призёр дипломнары белән бүләкләнгән команда кызлары - үз эшләренең осталары. 2019 нчы елда “Әллүки “ төркеме «Практикантлар килгән безгә” пьесасы белән ARTS BILER FORUMда катнашты һәм “Театр” юнәлешендә лауреат исеме белән бүләкләнде!

"Үсеш ноктасы" программасы буенча, мәктәптә "Креатив" театр түгәрәге эшен Заһидуллина Әлфия Гали кызы җитәкли. Ул алдагы уку елларында да үзе укыткан укучылар белән "Ният", зона бәйгеләрендә бик уңышлы чыгыш ясады. Аның укучылары җиңүчеләр рәтендә. 2018 нче елда Г. Камалның "Беренче театр" спектакле дебют номациясендә җиңүче булды. 2019 нчы елда Шамил Фәрхетдиновның "Алтын алма" әсәре буенча Зәйнуллин Рафаэль һәм Зәйнуллин Рәзилләр "Дуэт" номинациясендә җиңүчеләр. 2020 нче елда Т. Миңнуллинның "Кайда хаклык, кайда дәреслек?!" пьессасы буенча иң яхшы ир-ат роле номинациясендә җиңүче -Галиакбиров Рәсим. Ә бүген сәхнәдә яшьләр - 5 нче сыйныф укучылары. Т. Миңнуллинның "Үзем белән үзем" маҗаралы пьессасы белән уңышлы чыгыш ясап, күтәренке кәефтә уку елын тәмамлыйлар.



«Практикантлар килгән безгә»

2021

ГОД РОДНЫХ ЯЗЫКОВ И НАРОДНОГО ЕДИНСТВА
В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА
ТУГАН ТЕЛЛӘР ҺӘМ ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫ



“Кәрлә-мәктәп баласы”



«Авыл эте-Акбай»



"Үзем белән үзем"



Авылым тарихы



Бөек Җиңүнең 76 еллыгына

2021

ГОД РОДНЫХ ЯЗЫКОВ И НАРОДНОГО ЕДИНСТВА
В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА
ТУГАН ТЕЛЛӘР ҺӘМ ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫ

Г.Тукай иҗатына багышланган КВН.
Әзерләде: татар теле һәм әдәбияты укытучысы Заһидуллина Ә.Г.

*( Г. Тукайның “Тәфтиләү” көе әкрен генә уйнап тора)*

**Алып баручы:** Исәнмесез, хәерле көн! Татар халкының бөек шагыйре, әдәбиятыбызның йөзек кашы Габдулла Тукайга багышланган КВН ны бшлыйбыз.

**Алып баручы:** Йөрәкләрне дәртләндереп,
Тирә - якны ямьгә күмеп,
Шаулап – гөрләп,
Яз килә.

**Алып баручы:** Язның иң матур бер көнендә, карлар эреп, бозлар агып киткәч, агач һәм куаклар-да хуш исле бөреләр уянган чакта яраткан шагыйребез Габдулла Тукай туган.

**Алып баручы:** Бик еракта балкып аткан
Бер гүзәл апрель таңы,
Бирде сине бу җиһанга,
Ә шагыйрьләр солтаны.

**Алып баручы:** Шагыйрьләр солтаны булып
Тусаң да, Тукай, җиргә
Җәбер, золым, кимсенүләр
Туры килгән күрергә.

**Алып баручы:** Бәйрәмнәрең алда икән әле,
Кара, шагыйрь, бүген текәлеп,-
Халкың килде, сиңа мәхәббәтен
Ал чәчәкләр белән белдереп.

*(Кызлар башкаруында “Бәйрәм бүген” җыры яңгырый. Башкара Нургалиева Инзилә)*

**Алып баручы:** Хәзер КВН ны башлыйбыз. Ярышыр өчен классны икегә бүләбез. Рәхим итегез. ( укучылар чыга). Ә хәзер жирәбә алып командаларга бүленәбез.

**Алып баручы:** Хәзер һәр команда үзенең командирын, исемен, җырын сайлый һәм бер-берсен гадәттәгечә сәламли.

**Алып баручы:** Ярыш нәтиҗәләрен билгеләп бару өчен безгә жюри кирәк булачак. (балалар жюри членнарын үзләре тәкъдим итәләр)

**Уеннар:**

Һәр командага чиратлап сораулар бирелә:

- Габдулла Тукай укыган Уралскидагы мәдрәсәнең исеме ничек? (Мотыйгия)
- Г. Тукай яратып йөргән кызның исеме ничек? (Зәйтүнә)
- Тукайның кушаматы ничек булган? (Апуш)
- Г. Тукай туган авылны атагыз (Кушлавыч)
- Шагыйрь туган ел (1886 ел)
- Г.Тукайның әнисенең исеме ничек? (Мәмдүдә)
- “Бу авыл минем дөньяга иң элек күзем ачылган урын”-дип яза Тукай.Бу кайсы авыл? (Кырлай).
- Олуг шагыйребезнең кайсы шигырьләре көйгә салынган? ( “Туган тел», “Туган авыл”,”Пар ат”, “Бала белән күбәләк”....).
- Күренекле шагыйребез иҗатын халыкка танытуда зур эш башкарган әдип?(Әхмәт Фәйзи).

2021

ГОД РОДНЫХ ЯЗЫКОВ И НАРОДНОГО ЕДИНСТВА
В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА
ТУГАН ТЕЛЛӘР ҺӘМ ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫ

2. ”Тукайга ияреп”.
   Һәр команда 1куплет язга багышлап шигырь чыгара.
3. Һәр команда Тукай сүзләренә язылган бер җыр башкара.
4.”Су анасы”һәм “Шүрәле” әкиятләрен сәхнәләштереп күрсәтергә.(җирәбә белән алалар)
5. Ике командага да ”Пар ат” шигыре бирелә. Кайсы команда сәнгатьлерәк итеп укый.
6. Эш беткәч, уйнарга ярый” шигыре буенча рәсем ясау.(билгеле вакыт бирелә).
**Алып баручы:** сез рәсем ясаган арада безгә Сапарова Гүзәл «Шүрәле” поэмасыннан өзек укый.
7. Мәкальне дәвам итү.Һәр командага да тел турында мәкаль әйтелә.Мәкальнең башы әйтелә, ахырын дәвам итеп әйтеп бетерәсе.

Теле озын булмаганның ... (гомере озын булыр)
Теле озын кешенең ... (акылы кыска булыр)
Бер телдә ун хикмәт, .... (ун телдә йөз хикмәт)
Бит күрке күз, .... (тел күрке сүз)
Әдәп башы .... (тел)
Иле барның .... (теле бар)

8. Һәр команда бер – берсенә Габдулла Тукай иҗатына кагылышлы икешәр сорау бирә.
**Алып баручы:** Безнең уеннарыбыз тәмам. Жюри нәтиҗә ясаган арада без Минһаҗева Алсуның җырын тыңлыйк.
**Алып баручы:** Сүзне жюрига бирәбез. *(бүләкләр бирелә)*
**Алып баручы:** Туган телне күңел гөле итеп,
Саф көенчә сакла гомергә.
Рухи кыйблаң булсын – Тукай моңы,
Илең йөрсен уйда гел бергә.
**Алып баручы:** Син күрмәгән яңа буын килде.
Котлап бүген туган көнеңне.
Киләчәккә барган балалардан
Ишетәсең “Туган тел”еңне.




“Минем туган ягым-Татарстан”, “Туган телем-Тукай теле” муниципаль конкурсында 2 нче урынны алган укучылар: Залялиев И.,Сабирова К.,Замалетдинова А.,Нургалиева К.,Закиров Р.




Мәктәбебез укучысы Шәрәфиева Руфинә Казан шәһәрендә Тукай музеенда уздырылган бүләкләү тантанасында катнашты. Ул республикакүләм уздырылган конкурста 3 урынны яулады. Котлыйбыз!

2021

ГОД РОДНЫХ ЯЗЫКОВ И НАРОДНОГО ЕДИНСТВА
В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА
ТУГАН ТЕЛЛӘР ҺӘМ ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫ

***21 нче февраль –***
***Халыкара туган тел көне***
***Җыр булырлык сүзләр биргән,***
***Туган телем, рәхмәт сиңа!***
***(туган тел көненә багышланган кичә)***

**<u>Рамилә 5 кл.</u>**

Туган оясыннан аерылган кош
Канатына мәңге ял тапмый.
Туган телен яратмаган кеше,
Башкаларның телен яратмый.
Халкым теле миңа – хаклык теле.
Аннан башка минем телем юк.
Илен сөймәс кенә телен сөймәс,
Иле юкның гына теле юк.

**Рәзил 7 кл.**

21 нче февраль - Халыкара Туган тел көне. Бу көнне билгеләп үтү инициативасы белән Бангладеш Республикасы чыга. Анда 1957 нче елның 21нче февралендә, туган телдә белем алу хокукын даулап, биш студент һәлак була. Бу көн 2000 нче елдан башлап ЮНЕСКО карары нигезендә билгеләп үтелә башлады.

Шулай итеп, 2000 нче елда Берләшкән Милләтләр Оешмасы, ЮНЕСКО инициативасын хуплап, күптеллелекне яклау йөзеннән 21 нче февральне "Халыкара туган тел көне" итеп үткәрү турында карар кабул итте.

**Адилә 11кл**

Без-татарлар, туган телебез- татар теле.

Татар теле... Тугач та иң газиз кешеңнән ишетә башлаган, күп гасырлык тарихы булган, Каюм Насыйрилар, Тукайлар нигез салган, 7 миллион халык сөйләшкән, дөньядагы иң дәрәҗәле 14 тел исәбенә кергән, чит илләрдә дә өйрәнелә торган, бүгенге көндә җитлеккән, камилләшкән, теләсә нинди катлаулы фәнне өйрәтергә мөмкинлеге булган. Моабитның таш диварлары эчендә дә тынмыйча, аның калын стеналарын тишеп чыгып, бөтен дөньяга яңгыраган, утларга- суларга салсалар да, чукындырсалар да, ассалар-киссәләр дә исән калган, иң-иң авыр кимсетүчеләргә дә түзгән, сынмаган- сыгылмаган, баш имәгән горур татар теле! Бүгенге кичәбезне сиңа багышлыйбыз.

**Рәзил 9 кл.**

Кемнәр генә сиңа сокланмаган һәм мактау җырламаган?! Кемнәр генә синең ярдәмеңдә дөньяны танып белмәгән һәм үзенең уй – хисләрен башкаларга сөйләмәгән?!

Туган тел төшенчәсенә зур мәгънә салынган. Ул-Ватан, туган җир, ата-ана сүзләре белән белән бер үк дәрәҗәдә торучы бөек, изге һәм кадерле сүз. Ул телне шуңа күрә туган тел дип атыйлар да. Ул телгә баланы аның иң газиз, иң якын кешесе-анасы өйрәтә, шул телдә ана бишек җырларын җырлый, иркәли, юата. Шуңа күрә аны халык теле дип атый.

**Фирүзә 10 кл.**

Туган тел. Һәркем өчен дә газиз сүз бу. Чөнки иң кадерле, бернәрсә белән дә алыштырылмый торган "әни", "әти", "әби", "бабай" сүзләрен башлап туган телдә әйтәбез. Туган-үскән илҗирнең якынлыгын, Ватанның газизлеген без әүвәл туган тел ярдәмендә тойганбыз. Милләтебезнең сәнгать иҗаты... 

Милләтебезнең сәнгать иҗаты

Милләтебезнең сәнгать ияләренең матур-матур шигырьләрекн ятлап әле дә куанабыз, рухланабыз.

2021

ГОД РОДНЫХ ЯЗЫКОВ И НАРОДНОГО ЕДИНСТВА
В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА
ТУГАН ТЕЛЛӘР ҺӘМ ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫ

Ассалар да, киссәләр дә,
Үлмәдең син, калдың тере,
Чукындырылган чагында да
Чукынмадың татар теле.
**Альфир 6 кл.**
Яндың да син, туңдың да син,
Нишләтмәде язмыш сине,
Дөньяда күп нәрсә күрдең,
Әй, мөкатдәс Тукай теле.
Төрмәләргә дә яптылар
Җәлил белән белән бергә сине.
Төрмәдәләрдә дә килмешәк
Булмадың син, татар теле!
**Илмир 6 кл**.
Зинданнарны ярып чыктың,
Ялкынланып чыкты кире,
Хәтта фашист тегермәне
Тарта алмады анда сине,
Әй, син, батыр татар теле!
Кабатланмас үткәннәрнең–
Гасырларның яман чире.
Кабатлар сине гасырлар,
Татар теле, дуслык теле.
**Диана 3кл.**
Үз телемдә шигырь укыйм,
Үз телемдә сөйли алам.
Туган җирем, туган илем,
Мин бит синнән илһам алам.
Әткәм-әнкәм туып үскән,
Әби-бабай гомер кичкән.
Туган илем– татар җире,
Синнән матур ил бар микән?
**Филүс 2 кл.**
Мәчетләрнең очларында
Янып торган ярым айга
Карап, дога пышылдыймын:
“Иман китер имансызга”
Үз телемдә шигыйрь укыйм,
Үз телемдә сөйли алам.
Туган җирем– Татарстан,
Мин дә синең газиз балаң.

**Иллария 10 кл.**
Ана телем, сине өзелеп яратканга,
Очам дисәк, безгә булдың канатлар да;
Дошман белән көрәшкәндә– үткен кылыч,
Балдай татлы– дуслар белән сайрашканда.
Күңелләрдән күңелләргә юл саласың,
Сусаганда эссе чүлдә су табасың;
Алышларда арысланга тиңдәш итеп,
Тоткынлыкта тимер булып таш ярасың.
**Камилә 8 кл.**
Җырларның да иң яктысы синдә генә.
Уйларың да иң яктысы синдә генә.
Туган илнең, туган телнең матурлыгы
Якты илһам бирми икән кемгә генә!
Кайчагында адашкандай булам да мин,
Уңны-сулны шәйләмичә егылам, димен,
Туган телем балкыта да барыр юлны,
Күз алдында ярылып ята кыйблам минем.
**Инзилә 5 кл.**
И туган тел, и матур тел,
Әткәм- әнкәмнең теле-,
Дигән бөек Тукаебыз һәм ул мең тапкыр хаклы. Ни өчен? Чөнки кечкенәдән өйрәнелгән туган тел халык йөрәген шигърият белән сугарылып кына калмый, аның күңелендә милли горурлык хисләре дә уята, ата– бабаларыбыз теленнән рухи ләззәт алу мөмкинлеген бирә.
Тел– гомерлек юлдашыбыз. Әйе, кешенең бөтен тормышы тел белән бәйле. Туганнан алып соңгы сулышына кадәр тел һәм сүз– кешенең аерылгысыз юлдашы.
**Адилә 9 кл.** Хәзерге вакытта җир шарында 5500 тел бар дип исәпләнелә. ЮНЕСКО билгеләве буенча, шулар арасына кергән 14 телдә (гарәп, рус, немец, инглиз, француз, итальян, испан, португал, кытай, япон, татар, урду, бенгал, һинд) дөнья халкының 70 проценты сөйләшә.
Әгәр тарихка мөрәҗагать итсәк, шундый кызыклы гына фактларга тап булабыз. 16-17 гасырларда татар теле Россиядә рус теле белән беррәттән халыкара әһәмияткә ия булган.

**Илмир 7 кл.**
Татар теле үзенең үсеш дәверендә төрле кыенлыкларны, киртәләрне үтте. Халык күпме изелсә дә, ана телен саклап калды. Ә милләтнең саклануы турыдан –туры телгә бәйле. Чөнки гыйлем алу, аңны үстерү, дөньяны танып белү һәм аралашу туган тел аша тормышка ашырыла. Тел бетсә, милләт бетә, халык бетә.
Борынгы татар халык җырлары үзләренең моңлы яңгырашы белән безнең күңелләребезне айкап, тирән уйларга, кичерешләргә сала. Шушы моң халыкның хәтер кылларына кагыла да үткәннәрне бүгенге көн белән тоташтыра. (Татар халык җыры башкарыла).

**Зилә 3 кл.**
Асыл сүзләреңне, туган телем,
Биреп торчы миңа азга гына,
Бөтенләйгә түгел-вакытлыча,
Тик җитәрлек гомер азагыма.
Синнән алган һәрбер сүземне мин
Күз карасы төсле саклар идем,
Ул сүзләрнең затлыларын сайлап,
Дога итеп кенә ятлар идем.

**Риназ 4 кл.**
Ул сүзләрн җырга әйләндергәч,
Мин кайтарып сиңа бирәчәкмен.
Исраф булмас ул сүзләрең миндә,
Җыры булыр алар киләчәкнең.
Әйтә алмыйм әле: ул җырлардан
Аз булса да дөнья үзгәрерме?
Тик югалтмам, туган телем, синнән
Алып торган асыл сүзләремне.

**Рәсим 7 кл.**
Туган тел ул әһәңле дә, йомшак та ул,
Татлы да ул, гүяки бер ширбәт сыман.
Туган телем белем биргән чишмә дә ул,
Ныклап авыз итсәң әгәр шул саф судан.
Якты, нәфис сүзләрең күп, беләмен мин,
Шул сүзләрең белән данлыйм туган илне.
Синең белән сөям, җырлыйм, көләмен мин,
Синең белән котлыйм шат яңа көнне мин.

**Алмаз 1 кл.** Бергәләп җырлыйк “Туган тел” җырын,
Кечкенә чакта җырлаган кебек,
Сөенеп җырлыйк, туган тел җырын,
Онытканнарның бәгырен телик!
(“Туган тел” җыры башкарыла)





2021

ГОД РОДНЫХ ЯЗЫКОВ И НАРОДНОГО ЕДИНСТВА
В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА
ТУГАН ТЕЛЛӘР ҺӘМ ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫ

## Күңелем Тукай белән сөйләшә

Бусагадан атлап эчкэ узам..
башка донья, тылсым, моң, аһәң...
Бу - Тукайны хэтерлэткэн урын,
Бу-Тукайга булган зур хормэт!

Эчкэ узам, атлыйм түргэ таба,
Ә кузлэрем эзли Тукайны..
Кая соң син, Бөек шагыйребез?
Апуш исемле татар туганым!

Үзен юкны белэм...
Кунелем бит ышанырга һаман телэми
Рэсемнэрдэн карый япь-яшь Тукай.
Картаерга һич тэ уйламый!

Синең күзләр төпсез дэрья сыман.
Иҗатыңнын курэм дэвамын.
Оныкларын кулга калэм ала!
Синең эздэн бара кыз һэм улларын!

... Мин тукталып калдым, онсез торам-
Калэм савыты, калэм синеке?
куз алдыма килде тиз-тиз сырлаганың
Купме шигырь, купме экиятне.

Мең сынаулар узган житди йөзең,
Күзләреңдә курдем моң, сагыш.
Милләт, телнең курден киләчәген
Әйтелмичә калды купме суз...

Шушы калэм булды синең кулларында,
Сина улемсезлек теләде.
Мең рәхмәтле сиңа, Тукай әфәнде!
Мең рәхмәтле сиңа, тылсым каләме!

Шарафиева Рузинә, 6 нчы сыйныф укучысы




Победители муниципального конкурса «Читаем Тукая»- “Тукай укулары”
Шарафиева Рузина-1 место
Саетгараев Ильмир-1 место
Нургалиева Диана-1 место
Залялиева Зарина –2 место

13 апреля в Доме Актера им.М.Салимжанова состоялись прослушивания победителей муниципального этапа XI Международного конкурса «Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын» Г.Тукай /«Люби жизнь, народ и мир его» Г.Тукай. В мероприятии, приуроченном к Году родных языков и народного единства, из нашей школы участвовала обучающаяся 11 класса Ахметшина Адиля.



2021

ГОД РОДНЫХ ЯЗЫКОВ И НАРОДНОГО ЕДИНСТВА
В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА
ТУГАН ТЕЛЛӘР ҺӘМ ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫ

***Туган телем, тәмле телем,***
***Аһәңле һәм гамьле телем.***
***Туган җирдәй якын һәм үз,***
***Туган яктай ямьле телем.***








**Шагыйрь Исхак Фәйзуллин белән “Шигъри мәҗлес”**



2021

ГОД РОДНЫХ ЯЗЫКОВ И НАРОДНОГО ЕДИНСТВА
В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА
ТУГАН ТЕЛЛӘР ҺӘМ ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫ



**“Цветаева учаклары” конкурсының җиңүчесе 10 нчы сыйныф укучысы Гыйниятова Фирүзә, җитәкчесе Фәйзуллин И.И.**

**“Тимер юл" шигыренең 1нче кисәге**

**Ямьле дә соң бу көз! Саф һәм суык.**
**Җаннарга дәрт бирә һавасы.**
**Су өстенә яңа каткан бозны**
**Шикәр диеп килә кабасы.**

**Сузылып ятып бер йокларга була –**
**Җәймә кебек урман артлары.**
**Һава шарты яхшы. Җирдә яткан**
**Яфраклар да хәтта сап-сары.**

**Нинди шәп көз! Салкынчарак төннәр,**
**Һәм чалт аяз тыныч көннәре...**
**Бар да ямьле! Түмгәкләр һәм төпләр,**
**Мүкләр сарган сазлы күлләре...**

**Ай астында, ай-хай, бар да – матур!**
**Һәр тарафтан Рәсәй шәйләнә.**
**Юллар буйлап очам уйлар уйлап,**
**Шатлыгымнан башым әйләнә.**

***Николай Некрасов «Железная дорога»***

**Славная осень! Здоровый, ядреный**
**Воздух усталые силы бодрит;**
**Лед неокрепший на речке студеной**
**Словно как тающий сахар лежит;**

**Около леса, как в мягкой постели,**
**Выспаться можно — покой и простор!**
**Листья поблекнуть еще не успели,**
**Желты и свежи лежат, как ковер.**


**Славная осень! Морозные ночи,**
**Ясные, тихие дни…**
**Нет безобразья в природе! И кочи,**
**И моховые болота, и пни —**

**Всё хорошо под сиянием лунным,**
**Всюду родимую Русь узнаю…**
**Быстро лечу я по рельсам чугунным,**
**Думаю думу свою…**

2021

ГОД РОДНЫХ ЯЗЫКОВ И НАРОДНОГО ЕДИНСТВА
В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА
ТУГАН ТЕЛЛӘР ҺӘМ ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫ

**Республикакүләм үздырылган “Муса Җәлил” укуларының муниципаль этабында 9 нчы сыйныфтан Галиакбиров Р.Р., 11 нче сыйныфтан Шәйхетдинова Ф.И. 2 , Гаязова Г.Р. 3 нче урыннарны яулады.**
**VIII балалар әдәби премиясе “Глаголица” конкурсында 7 нче сыйныфтан Заһидуллина А.Р. кыска исемлеккә эләгеп, Лаеш районындагы “Йолдызлы”**







**“Коррупциягә каршы көрәш» бәйгесендә 11 нче сыйныф укучысы Шәйхетдинова Гөлгенә 2 нче урынны алды, җитәкче Гарифуллина Л.Р.**




МКУ «Отдел образования Исполнительного комитета Тетюшского муниципального района Республики Татарстан»

Диплом

ВРУЧАЕТСЯ

Шайхутдиновой Гульгене,
*обучающейся 9 класса*
*МБОУ «Алабердинская средняя общеобразовательная школа»*
*(руководитель: Гарифуллина Л.Р.)*

за II место
*в муниципальном этапе Республиканского конкурса творческих работ (сочинений-эссе) антикоррупционной направленности обучающихся национальных школ на родном языке «Скажем коррупции «Нет!» (Номинация «На страже закона»).*

*Начальник* *Г.Ф. Кирилина*

*Приказ от 30 сентября 2021 г. №501/1-о/д*




МУНИЦИПАЛЬНОЕ КАЗЕННОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ «ОТДЕЛ ОБРАЗОВАНИЯ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН»

СЕРТИФИКАТ
УЧАСТНИКА
вручается

коллективу «Креатив»
МБОУ «Алабердинская СОШ»
(руководитель Загидуллина А.Г.)
в возрастной категории
«5-8 классы общеобразовательных организаций»
муниципального этапа республиканского фестиваля детских юношеских театров «СӘЙЯР»

Начальник Г.Ф. Кирилина

Приказ № 517 о/д от 11.10.2021г.

2021

ГОД РОДНЫХ ЯЗЫКОВ И НАРОДНОГО ЕДИНСТВА
В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА
ТУГАН ТЕЛЛӘР ҺӘМ ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫ

**“Милләт курчагы” һәм “Татарстан талантлары” конкурсында 1 нче сыйныфтан Нигматуллина Диләрә, 7 нче сыйныфтан Заһидуллина Алия**



**Туган телем**

**Туган телем, сөйгән телем,
Кечкенәдән белгән телем,
Күзәнәкләремә кадәр
Бар тәнемә сеңгән телем.**

**Туган телем, газиз телем,
Тыңлап туймас нәфис телем.
Синең аша кемдер дәшсә,
Нурга чума нәүмиз көнем.**

**Туган телем, матур телем,
Җанга майдай ятыр телем.
Күпчелек сабыр булсаң да,
Кирәк чакта батыр телем.**

**Туган телем, тәмле телем,
Аһәңле һәм гамьле телем.
Туган җирдәй якын һәм үз,
Туган яктай ямьле телем.**

**Туган телем, көчле телем,
Изге рухлы, хисле телем.
"Милләтемне сакла", – диеп
Дога кылыр дисбе телем.**

**Туган телем, тамыр телем,
Нәсел буйлап калыр телем.
Юлларымда юлдаш булып,
Гел янымда барыр телем.**

**(Исхак Фәйзи)**

2021

ГОД РОДНЫХ ЯЗЫКОВ И НАРОДНОГО ЕДИНСТВА
В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА
ТУГАН ТЕЛЛӘРҺӘМ ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫ




26 апреля – знаменательная дата – День родного языка, приуроченный ко дню рождения великого татарского поэта, одного из основоположников современного татарского литературного языка Габдуллы Тукая. В этом году исполняется 135 лет со дня рождения классика татарской поэзии, публициста и общественного деятеля.

Стало доброй традицией проведение разнообразных мероприятий, в которых мог бы принять участие каждый желающий. Учащиеся нашей школы активно принимали участие во всех этих

16 апреля 2021 года Шайхутдинова Фирюза, ученица 10 класса, приняла участие в конференции X республиканские научно-исследовательские чтения имени Г.Тукая, которая проходила в с. Новый Кырлай Арского района, на родине великого татарского поэта Габдуллы Тукая.





Нинди генә очракта да җиңәргә өйрән! Көчле рухлылар гына максатларына ирешә алалар. Түземнәр генә бәхеткә лаек!
Фәнис Яруллин



И Туган тел, и матур тел,
Әткәм-әнкәмнең теле.
Дөньяда күп нәрсә белдем
Син туган тел аркылы!
Габдулла Тукай

Ответственные за выпуск:
Гарифуллина Л.Р
Гарифуллина Э.Х.

Наш адрес:
422373 Республика Татарстан, Тетюшский район, с. Алабердино, ул. Хусаинова, 40, МБОУ «Алабердинская СОШ»,
Телефон: +7(843)-735-80-26
SAlaberd.Tet@tatar.ru